**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Карамалы авыл җирлеге Советы**
**КАРАР**

**2018 елның 4 сентябре** **№ 72**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамал авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 44 маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү (1 нче кушымта).

2. Кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына җибәрергә.

3. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе исеменнән түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Карамал авылы, Үзәк урам, 4 йорт, мәдәният йорты бинасы;
- ТР, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы , Тукай урамы, 16 йорт, авыл кибете бинасы һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башлыгы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы рәисе** **Э. И. Байдамшин**

2009 елның 4 сентябрендәге72-ТРЗ
номерлы “Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамал авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү
турында”гы Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге
Советы карарына кушымта

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 7 маддәдә:

а) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру”;

б) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“14) җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм каты коммуналь калдыкларны транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;”.

2. 8 маддәдә:

а) 1 маддәнең бер өлешен түбәндәге эчтәлекле 16 пункт белән тулыландырырга:

“16) инвалидлар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар, адаптив физик культура һәм адаптив спорт үсешенә ярдәм күрсәтү.”;

б) 12 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3. 14 маддәдә:

а) 7 пунктны “, иҗтимагый фикер алышулар” сүзләре белән тулыландырырга”;

б) 8 пунктка “, гражданнар җыены” сүзләрен өстәргә.

4. 23 маддәдә:

а) маддәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар”;

б) 3 өлеш:

1) түбәндәге эчтәлекле 2.1 пунктын өстәргә:

“2.1) җирлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты”

2) 3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

“3.1. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә, җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш объектларының чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турында карар проектлары буенча, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән башка төр файдалану мәсьәләләре буенча җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланган кагыйдәләре булмаганда,иҗтимагый фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе әлеге маддәнең 4-10 өлешләре нигезендә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнә.”.

5. II бүлек. Җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы рәвешләрен түбәндәге эчтәлекле 24.1 маддә белән тулыландырырга: “гражданнар җыены”:

“1. Гражданнар җыены җирле үзидарәне халык тарафыннан турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда халыкның катнашуы формасы булып тора.

2. Гражданнар җыены “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законда каралган очракларда һәм җирлек Советы карары белән расланган Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

3. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1 маддәсендә каралган очракларда гражданнар җыены үткәрелергә мөмкин:

1) составына күрсәтелгән торак пункт керә торган авыл җирлеге (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча әлеге торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертеп була торган торак пунктта;

2) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә күрсәтелгән җирлекнең чикләрен үзгәртү мәсьәләләре буенча;

3) сайлау хокукына ия җирлек халкы саны 100 дән артык кеше булса, җирле үзидарәнең вәкиллекле органын төзү, аның саны һәм вәкаләтләре вакыты турындагы мәсьәлә буенча гражданнар җыенында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гамәлгә ашырыла;

4) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

5) авыл җирлеге составына, шәһәр эчендәге район, федераль әһәмияттәге шәһәр округы территориясе, яисә муниципаль район чикләрендә урнашкан торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

6) халык инициативасын җирле үзидарәне оештыру һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча шәһәрара территориядә урнашкан торак пунктта күрсәтү максатларында;

7) авыл җирлеге халкы 100 дән артмаган булса, авыл халкының тыгызлыгы түбән булган территориядә урнашкан авыл җирлеген бетерү мәсьәләсе буенча;

8) авыл җирлеге авыл торак пункты старостасы кандидатурасын тәкъдим итү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

9) авыл торак пунктында гражданнар җыены шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар тәкъдим итү максатларында үткәрелә ала.

4. Гражданнар җыены җирлек башлыгы тарафыннан яисә сайлау хокукына ия, кимендә 10 кеше булган торак пункт халкы төркеме инициативасы белән чакырыла ала.

5. Җыен үткәрү инициативасына ярдәм итәргә тиешле имзалар саны сайлау хокукына ия, даими яки нигездә торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар саныннан 5 процент тәшкил итә, ләкин 25тән дә ким булырга тиеш түгел.

6. Җирлек башлыгы тарафыннан тәкъдим ителә торган гражданнар җыены җирлек башлыгы карары белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан бирелә торган гражданнар җыены җирлек Советы карары белән билгеләнә.

7. Торак пунктта яшәүчеләр гражданнар җыеннарын үткәрү вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителәләр, гражданнар җыеннарын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында Нигезләмә нигезендә гражданнарны кабул итүгә чыгарыла торган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый акт проекты һәм материаллар белән алдан ук таныштыралар.

8. Җыенда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып торалар, җирлек башлыгы тарафыннан имзаланалар һәм Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш булалар.”.

6. 3 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5) җирлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау;”;

б) түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункты белән тулыландырырга:

“5.1) җирлекнең муниципаль идарәсе һәм социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы максатларын һәм бурычларын билгеләү, җирлек җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын карау һәм раслау;”;

в) 36 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“36) җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау”;

г) 38 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“38) җирлекнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү программаларын, җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын, җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын раслау, аларга карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;”.

7. 47 маддәнең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“10) җирлек Советы каравына җирлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проектын тәкъдим итә;”.

8. 53 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәпкә алу өлкәсендә:

- җирлек бюджеты проектын, җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын эшли;

- җирлек бюджетының үтәлешен тәэмин итә, җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен тормышка ашыруны оештыра;

- җирлек бюджетының үтәлеше, җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен үтәү турында отчет әзерли;

- җирлекнең икътисад һәм социаль өлкә торышын характерлаучы статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына бирүне оештыра;

- җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча стратегик планлаштыру документларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

- җирлек Советы тарафыннан расланган (хупланган) стратегик планлаштыру документларын тормышка ашыруны мониторинглау һәм контрольдә тоту;”;

б) 1 өлешнең 5 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә җирлек территориясен төзекләндерү эшчәнлеген оештыра;”;

в) 1 өлешнең 8 пунктчасының 2 абзацы үз көчен югалткан дип танырга.

9. 54 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“54. Җирлек Башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары

Башкарма комитет җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

- җирлек музейларын булдыра;

- җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кыла;

- опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне тормышка ашыруда катнаша;

- җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләр хокукларын гамәлгә ашыру белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

-Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә чараларны тормышка ашыруга булышлык күрсәтә;

- җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү буенча чараларны оештыруда һәм тормышка ашыруда катнаша;

- муниципаль Янгын сагы булдыра;

- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

- кеше хокукларын тәэмин итүгә иҗтимагый контроль һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм итүче иҗтимагый күзәтү комиссияләренә булышлык күрсәтә;

- инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”гы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия иҗтимагый берләшмәләре оештырган оешмаларга ярдәм күрсәтә”;

- гражданнарга торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарын найм килешүләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын тәкъдим итә;

- җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чараларны гамәлгә ашыра;

- 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында”гы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыра”;

- инвалидлар, сәламәтлекләре чикләнгән затлар, адаптив физик культура һәм адаптив спорт үсешенә булышлык күрсәтә.”

10. 73 маддәнең 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, гамәлгә куючы булып торучы җирлек торган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан итү) үз көченә керә.”.

11. 83 маддәдә:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен гражданнарның бер тапкыр түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салым түләүләре күләме җирлек составына кергән торак пунктның барлык халкы өчен дә (җирлек составына керә торган торак пункт) абсолют зурлыкта билгеләнә, аларның саны җирлек составына керүче торак пунктларның (торак пунктның) гомуми санынннан 30 проценттан артып китә алмый һәм алар өчен түләү күләме кимергә мөмкин”.

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Әлеге маддәнең 1 өлешендә күрсәтелгән гражданнарга бер тапкыр бирелә торган түләүләрне кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә, ә 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1 маддәсендәге 1 өлешенең 4.1 пунктында каралган очракларда гражданнар җыенында хәл ителә”.

12. 88 маддәнең 3 өлешендә икенче тәкъдимне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук муниципаль берәмлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы

законнары нигезләмәләрен төгәл күрсәтү рәвешендә үзгәрешләр кертелә торган очракта, гражданнарның аның фикер алышуында катнашу тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) таләп ителми.”.

13. 90 маддәдә:

а) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Әлеге уставка кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү (җирлек уставын федераль законнарга туры китерү, шулай ук вәкаләтләрне, вәкаләтләр срогын, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын сайлау тәртибен үзгәртү очракларыннан тыш) әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр әлеге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый актка кул куйган җирлек башлыгы вәкаләтләре срогы чыкканнан соң үз көченә керә.”;

б) түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

“3.1. Әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр муниципаль хокукый акт тарафыннан кертелә, ул рәсмиләштерелергә мөмкин:

1) аның рәисе һәм җирлеге башлыгы кул куйган җирлек Советы (гражданнар җыены) карары я җирлек башлыгы, җирлек Советы рәисе вәкаләтләрен башкаручы (гражданнар җыены) ;

2) Совет тарафыннан кабул ителгән һәм җирлек башлыгы кул куйган аерым норматив хокукый акт. Бу очракта әлеге хокукый актта Совет (гражданнар җыенында) аны кабул итү турында карарның реквизитлары куела. Советның мондый карарына күчеш нигезләмәләрен һәм (яки) җирлек уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр үз көченә керү турындагы нормаларны кертү рөхсәт ителми.”;

в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

“5. Авыл җирлеге уставын Федераль законга туры китерү, Татарстан Республикасы законы белән әлеге закон актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Әгәр федераль закон, Татарстан Республикасы законы белән күрсәтелгән срок билгеләнмәгән булса, җирлек уставын Федераль законга туры китерү вакыты Татарстан Республикасы законы белән тиешле федераль закон, Татарстан Республикасы Законы үз көченә керү датасын, җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу турында муниципаль хокукый акт проектының ачык тыңлауларында фикер алышуны, җирлек Советы утырышларының вакытлылыгы исәпкә алынуын исәпкә алып билгеләнә, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәвенә алу һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка игълан итү) сроклары, кагыйдә буларак, алты айдан да артмаска тиеш.”;

г) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш белән тулыландырырга:

“6. Җирлек Уставын яңа редакциядә бәян итү җирлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт белән рөхсәт ителми. Бу очракта җирлекнең яңа Уставы кабул ителә, ә элек җирлекнең гамәлдәге Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актлар җирлекнең яңа Уставы үз көченә кергән көннән үз көчен югалткан дип танылган.”.